**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 25 февраль | № 113

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 8 май, 307 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 8 май, 307 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 8 октябрь, 744 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәдә:

1 бүлекнең 1.2 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Дәүләт комитеты юридик зат булып тора, аның Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнгән һәм үз исеме язылган мөһере, билгеләнгән үрнәктәге штамплары һәм бланклары, гамәлдәге законнар нигезендә ачыла торган исәпләре була.»;

3 бүлекнең 3.1 нче пунктында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль закон һәм Татарстан Республикасы заказчылары ихтыяҗлары өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алулар турындагы Татарстан Республикасы норматив хокук актлары нигезендә Дәүләт комитеты төп функция – Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру өчен җавап бирә (03.05.05 <*>), шул исәптән:»;

түбәндәге эчтәлекле 3.1.9 нчы пунктча өстәргә:

«3.1.9. «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль законның 81 статьясы белән

билгеләнгән тәртиптә гуманитар ярдәм күрсәтү йә табигый яки техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр салган зыяннарны бетерү максатларында сатып алуларда катнашучыларны алдан сайлау алу үткәрүне гамәлгә ашыра.»;

5 бүлекнең 5.3 нче пунктындагы «финанслау» сүзен «эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары, Татарстан Республикасы бюджет учреждениеләре ихтыяҗлары өчен кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) үзәкләштереп билгеләүне һәм алар өчен Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү функцияләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы заказчылары ихтыяҗлары өчен кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләүне оештыру тәртибендә:

1 бүлектә:

өченче абзацка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Моның белән бергә заказчылар Федераль законның 93 статьясындагы 1 өлешнең 4 нче һәм 5 нче пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы заказчылары ихтыяҗлары өчен үзәкләштереп сатып алына торган товарларның, заказ бирелә торган эшләрнең һәм хезмәт күрсәтүләрнең детальләштерелгән исемлегенә кертелгән товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алуларны гамәлгә ашыра ала;»;

дүртенче абзацка «кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны)» сүзләреннән соң «контрактның башлангыч (максималь) бәясе 10 мең сумнан артмаган» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Аларның ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты кайтартучылар (подрядчылар, башкаручылар) билгеләү функцияләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы дәүләт заказчылары һәм Татарстан Республикасы бюджет учреждениеләре исемлегендә:

6 нчы пункттагы «вәкаләтле вәкил» сүзләрен «вәкаләтле вәкил аппараты» сүзләренә алыштырырга;

26 нчы пункт үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\113.doc